**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02 апрель 2026ел. № 100

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының 20.05.2025 №150 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.08.2018 ел, № 665 карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 22 сентябрендәге 720 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының 20.05.2025 №150 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«II. Яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү**

2.1. Яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары"һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| "Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары"һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |

| | |
|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |

2.2. Яшьләр сәясәте оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 26 090 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча Инструктор | 27 390 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | 27 500 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга өстәмә белем бирү уку-укыту программасын һәм уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 27 890 |

"Яшьләр белән эшләү белгече" һәм "яшьләр белән социаль эшләү белгече" вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрнең база окладлы 27500 сум тәшкил итә.

2.3. Яшьләр сәясәте оешмаларының медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| "Урта медицина һәм фармацевтика персоналы"һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать Туташы | 27 760 |

| "Табиблар һәм провизорлар"һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 32 090 |

Яшьләр сәясәте оешмаларының медицина хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла. Тармакның өстенлек коэффициенты күләме 1,1 тәшкил итә.

Күрсәтелгән коэффициентны база окладына куллану яңа база оклады барлыкка китерә һәм компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр исәпләгәндә исәпкә алына.

1.2. 16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Таблица 16

**Яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең база окладлары күләмнәре**

| п/п | Атама оешма тибы/оешманың штат саны, берәмлек | Хезмәт өчен түләү Төркеме | Җитәкченең база оклады<*>, сум |
|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 |
| | Сәламәтләндерү-ял итү учреждениеләре (лагерьлар) | | |
| | 10 кешегә кадәр | 1 | 41 140 |
| | 11 дән | 2 | 44 170 |
| <*> Яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары җитәкчеләре өчен башкарылган эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятен исәпкә алып, шулай ук яшьләр сәясәте муниципаль оешмаларына эшчәнлек профиле буенча оештыру һәм методик ярдәм күрсәтүгә бәйле рәвештә база окладына карата 1,1 күләмендә арттыру коэффициенты билгеләнә.» | | | |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan,ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов